ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 164-VII ДС

2024 елның 23 декабрендәге
164-VII ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карары
белән расланды

**2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы**

| № т/б | Чара исеме | Үткәрү вакытлары | Җаваплылар |
|---|---|---|---|

**1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының хезмәттәшлек турында килешүләр төзегән Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары белән хезмәттәшлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.1. | Хезмәттәшлек турында килешүләрне һәм беркетмәләрне гамәлгә ашыру буенча уртак эшче комиссияләр төзү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 1.2. | Татарстан Республикасы парламент делегацияләренең Россия Федерациясе субъектларына һәм чит илләргә визитларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру (рәсми чакырулар буенча) | | |
| 1.3. | Закон чыгару эшчәнлеге мәсьәләләре буенча уртак конференцияләр, семинарлар, «түгәрәк өстәл»ләр үткәрү | | |
| 1.4. | Закон актларын һәм эчке куллану документларын | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (парламентлар регламентларын, комитетлар һәм комиссияләр турында, аппаратлар хакында нигезләмәләрне һ.б.), парламент эшчәнлеге турында мәгълүмати-аналитик материалларны, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кергән закон чыгару инициативалары проектларын алмашу | | |

**2. Парламентара бәйләнешләрне үстерү**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.1. | Россия Федерациясе субъектлары һәм чит дәүләтләр парламент делегацияләренең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 30 еллыгына багышланган чараларда катнашуы | март | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 2.2. | Мәгълүмат һәм башка элемтәләрне киңәйтү, тәҗрибә өйрәнү һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары (Мәскәү шәһәре, Санкт-Петербург шәһәре, Тверь өлкәсе), чит дәүләтләр һәм чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | парламентлары (Иран Ислам Республикасы, Казахстан Республикасы, Таҗикстан Республикасы, Үзбәкстан Республикасы, Төрекмәнстан) белән хезмәттәшлекне үстерү | | |
| 2.3. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Каракалпакстан Республикасы Жокаргы Кенес (Үзбәкстан Республикасы) белән парламентара хезмәттәшлеген үстерү буенча эшче төркем эшчәнлеген тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтов |
| 2.4. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында чит дәүләтләр делегацияләрен кабул итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 2.5. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасы Рәисе җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы рәсми делегацияләре визитларында катнашуы | ел дәвамында (аерым график буенча) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Республикасы Рәисе Администрациясе |
| 2.6. | Беларусь һәм Россия регионнарының XII Форумы чараларында катнашу (Түбән Новгород шәһәре) | якынча 25 – 27 июнь | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретариаты |
| 2.7. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының халыкара форумнарда һәм конференцияләрдә катнашуы. Килә торган делегацияләр белән эшләү, чит ил парламент делегацияләре һәм Россия Федерациясе субъектлары делегацияләре визитлары кысаларында депутат коллегалар белән очрашулар һәм консультацияләр | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

**3. Парламент оешмалары белән хезмәттәшлек**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.1. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Россия Федерациясе Федераль Собраниесе каршындагы Россия Федерациясе Закон чыгаручылар советы эшендә катнашуы. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары җитәкчеләре белән | Закон чыгаручылар советы эше планы нигезендә ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе (Халыкара хезмәттәшлек проблемалары комиссиясе рәисе һәм Закон чыгаручылар советы Президиумы әгъзасы буларак), Татарстан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | очрашулар. Россия Федерациясе Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары комиссиясе эшен оештыру | | Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 3.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары ассоциациясе эшендә катнашуы. Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары җитәкчеләре белән очрашулар | Ассоциация утырышлары планы нигезендә ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариатының аналитика бүлеге |
| 3.3 | Идел буе федераль округы Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең Закон чыгару органнары ассоциациясенең LXXVIII утырышын Казан шәһәрендә үткәрү | декабрь | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе |

## 4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының һәм комиссияләренең парламентара хезмәттәшлеге

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.1. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советының һәм Дәүләт Думасының профильле комитетлары белән хезмәттәшлеге. Парламент тыңлауларында, «түгәрәк өстәл»ләрдә, конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашу | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 4.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының Россия Федерациясе субъектлары парламентларының, шул исәптән Идел буе федераль округы составына керүче, профильле комитетлары (комиссияләре) белән хезмәттәшлеге | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 4.3. | Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенең профильле комитеты белән уртак күчмә утырыш үткәрү | июнь | Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты |
| 4.4. | Түбәндәге мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсен өйрәнү: | | |
| | инициативалы проектлар өлешендә җирле үзидарә | ел дәвамында | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турындагы законнарны гамәлгә ашыру | | комитеты |
| | Россия Федерациясе республикаларын конституциячел-хокукый үстерү, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары тарафыннан законнар торышы турындагы докладларны хокукый мониторинглауны һәм әзерләүне гамәлгә ашыру тәҗрибәсен өйрәнү | | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |

**5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәләренең парламентара хезмәттәшлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5.1. | Россия Федерациясе субъектларында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясе депутат берләшмәләренең региональ координация советлары линиясе буенча үзара хезмәттәшлек | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Единая Россия» фракциясе җитәкчесе |
| 5.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе һәм Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару органнарының хатын-кыз депутатлары катнашында дискуссия мәйданчыклары утырышлары | квартал саен | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5.3. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлары берләшмәсенең Халыкара хатын-кызлар клубы катнашучылары белән хезмәттәшлеге | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе |
| 5.4 | Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары (Башкортостан Республикасы, Марий Эл Республикасы, Удмуртия Республикасы, Чуваш Республикасы) КПРФ фракцияләре депутатлары белән торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе җитәкчесе |

**6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының парламентара хезмәттәшлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6.1. | Санкт-Петербург Закон чыгару Собраниесе, Мәскәү өлкә Думасы, Самара Губерна Думасы аппаратларының эш тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Оештыру идарәсе |
| 6.2. | Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару органнарының хокукый хезмәтләр җитәкчеләренең еллык | II квартал | Хокук идарәсе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | киңәшмәсендә катнашу | | |
| 6.3. | Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару органнары аппаратының кадрлар хезмәте җитәкчеләренең еллык киңәшмәсендә катнашу | II квартал | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 6.4. | Зур региональ һәм округ парламент чараларын әзерләү һәм үткәрү үзенчәлекләрен өйрәнү (Оренбург, Пенза өлкәләре дәүләт хакимияте закон чыгару органнары мисалында) | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариатының аналитика бүлеге |
| 6.5. | Электрон документ әйләнеше системасында эшләү, документлар үтәлешен тикшереп тору, эш номенклатурасын төзү, закон проектларына лингвистик экспертиза уздыру, утырышларның стенографик хисапларын әзерләү өлешендә Мәскәү шәһәр Думасы, Түбән Новгород өлкәсе Закон чыгару Собраниесе аппаратларының эш тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Документлар белән тәэмин итү идарәсе |
| 6.6. | Үз эшчәнлекләрен цифрлаштыру мәсьәләләре буенча Самара Губерна Думасының, шулай ук | ел дәвамында | Эшләр идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеген |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарының, чит дәүләтләрнең тәҗрибәсен өйрәнү | | мәгълүмати-технологик тәэмин итү бүлеге |
| 6.7. | Идел буе федераль округы Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары матбугат хезмәтләренең Идел буе федераль округы Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары ассоциациясе утырышларында катнашу кысаларында массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү өлкәсендәге эш тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Матбугат хезмәте |